**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының аларны биләгәндә Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау хакында**

“Коррупциягә каршы көрәш турында” 25.12.2008 ел, №273-ФЗ Федераль законны, “Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте турында” 27.07.2004 ел, №79-ФЗ Федераль законны, “Коррупциягә каршы көрәш буенча Россия Федерациясенең аерым закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү турында” 22.12.2014 ел, №431-ФЗ Федераль законны, Россия Федерациясе Президентының “Коррупциягә каршы көрәш турында” Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру хакында” 21.07.2010 ел, №925 Указын, Татарстан Республикасы Президентының “Татарстан Республикасының аларга билгеләнгәндә гражданнар һәм аларны биләгәндә Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау хакында” 30.12.2009 ел, №ПУ-701 Указын, Татарстан Республикасы Президентының “Татарстан Республикасының аларны биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең чыгымнары турында белешмәләр, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау хакында” 22.04.2013 ел, №ПУ-329 Указын үтәп, шулай ук Татарстан Республикасы Президентының “Татарстан Республикасында җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә дәүләт идарәсе мәсьәләләре” хакында 28.11.2014 ел, №ПУ-1091 Указы, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының (алга таба – Министрлык) “Штат расписаниесенә үзгәрешләр кертү турында” 15.12.2014 ел, №906-п боерыгы нигезендә

**БОЕРАМ:**

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының аларны биләгәндә Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген (алга таба – Исемлек) расларга.

2. Исемлеккә кертелгән вазифаларны биләүче дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә түбәндәгеләрне аңлатырга:

Исемлеккә кертелгән дәүләт гражданлык хезмәте вазифасын биләгән граждан, дәүләт гражданлык хезмәтеннән куылганнан соң ике ел дәвамында, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясенең ризалыгы белән, хезмәт шартнамәсе шартларында оешмаларда вазифалар биләү һәм (яки) әлеге оешмада ай дәвамында гражданлык-хокукый шартнамә (гражданлык-хокукый шартнамәләр) шартларында йөз мең сумнан артык хаклы эшләр эшләү (әлеге оешмага хезмәтләр күрсәтү) хокукына ия, әгәр дә әлеге оешманың дәүләт идарәсендәге аерым функцияләр дәүләт гражданлык хезмәткәренең вазифаи (хезмәт) бурычларына кергән булса;

дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын биләгән граждан, Исемлек нигезендә, дәүләт гражданлык хезмәтеннән куылганнан соң ике ел дәвамында әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән эшләрне башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) хезмәт яки гражданлык-хокукый шартнамәләр төзегәндә эш бирүчегә үзенең соңгы хезмәт итү урыны турында белешмәләр җиткерергә бурычлы;

Исемлеккә кертелгән дәүләт гражданлык вазифасын биләгән гражданның дәүләт гражданлык хезмәтеннән куылганнан соң ике ел дәвамында әлеге пунктның өченче абзацында каралган таләпне үтәмәве күрсәтелгән граждан белән төзелгән әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән эшләрне башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) хезмәт яки гражданлык-хокукый шартнамәләрне өзүгә сәбәп була.

3. Документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлегенә (Г.Р.Хәннанова) боерыкны Министрлыкның Исемлеккә кертелгән дәүләт гражданлык хезмәткәрләре игътибарына җиткерергә.

4. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә (Ш.К.Сәлимгәрәев) боерыкның күчермәсен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынганнан соң өч көнлек срокта, Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсенә җибәрергә.

5. Министрлыкның “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының аларга билгеләнгәндә гражданнар үзләренең керемнәре, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга, шулай ук аларны биләгәндә дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республика дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау хакында”гы 09.01.2014 ел, №1-п боерыгын гамәлдән чыккан дип танырга.

6. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Министр А.Г.Сидоров

Татарстан Республикасы Экология
һәм табигый ресурслар
министрлыгының 2015 елның
“__” ______________ №____
боерыгына кушымта

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының аларны биләгәндә Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеге**

**Дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларының иң югары төркеме:**
министрның беренче урынбасары,
министр урынбасары.

**Дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларының төп төркеме:**
эшләр белән идарә итүче,
Икътисад һәм инвестиция эшчәнлеге идарәсе башлыгы,
Дәүләт экология экспертизасы һәм әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны нормалаштыру идарәсе башлыгы,
Әйләнә-тирә мохитне саклау идарәсе башлыгы,
Минерал-чимал һәм су ресурслары идарәсе башлыгы,
Җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу идарәсе башлыгы,
финанс контрольлеге, исәпкә алу һәм хисапнамә бүлеге башлыгы,
хокукый тәэминат бүлеге башлыгы,
Дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясе башлыгы,
территориаль идарә башлыгы.

**Дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларының әйдәп баручы төркеме:**
министр ярдәмчесе,
финанс контрольлеге, исәпкә алу һәм хисапнамә бүлеге башлыгы урынбасары,
әйләнә-тирә мохит икътисады бүлеге башлыгы,
инвестиция программаларын үтәү бүлеге башлыгы,
дәүләт заказы, конкурс торглары бүлеге башлыгы,
дәүләт экология экспертизасы бүлеге башлыгы,
әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны нормалаштыру бүлеге башлыгы,
атмосфера һавасын саклау бүлеге башлыгы,

су объектларын саклау бүлеге башлыгы,
җир ресурсларын саклау бүлеге башлыгы,
углеводород чималы геологиясе бүлеге башлыгы,
каты казылма байлыклар геологиясе бүлеге башлыгы,
гидрогеология һәм судан файдалануны җайга салу бүлеге башлыгы,
җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлеге башлыгы,
мәгълүмати геологик ресурслар һәм геологик тирәлек мониторингы бүлеге башлыгы,
җир асты байлыгыннан файдалануны үстерү бүлеге башлыгы,
административ бүлек башлыгы,
территориаль идарә башлыгы урынбасары,
Дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясе башлыгы урынбасары.

**Дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларының өлкән төркеме:**
Дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясенең 2 разрядлы өлкән белгече,
Дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясенең 3 разрядлы өлкән белгече,
территориаль идарәнең 2 разрядлы өлкән белгече,
территориаль идарәнең 3 разрядлы өлкән белгече.

**Дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларының кече төркеме:**
территориаль идарәнең 1 разрядлы белгече.